СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**22.09.2017 ел** **№ 39**

**Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2018 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү гә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | - янгын гидранты урнаштыру<br>Штерә авылы<br>Иске Чүриле авылы |

| | | |
|---|---|---|
| 2 | Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | -торак пунктларда автомобиль юл-урам челтәреннән вак таш сатып алу, нигез һәм юл өслеге салу буенча хезмәтләр күрсәтү:<br>Иске Чүриле авылы, Зеленая ур., (52А-56, 8-22)<br>Иске Чүриле авылы, Яңа урамы (34-48)<br>Ашабаш авылы, Комсомол урамы (150 м)<br>Михайловка п., Түбән ур. (500 м)<br>Штерә авылы, Совет ур., (67-93) |
| 3 | Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (шул исәптән урамнарны яктырту) | - торак пунктларда урамнарны яктырту:<br>Штерә авылы,<br>Ермоловка авылы |

Әйе Юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күплән җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Яңа ур., 52; ТР, Арча районы, Штерә авылы, Совет ур., 30; ТР, Арча районы, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4а; ТР, Арча районы, Венета авылы, Үзәк урамы, 13

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Заһидуллина

СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ